ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/8

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар хакында

Гражданнарның һәм физик затларның мәнфәгатьләренә кагылышлы җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру һәм шәһәр территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу тәртибен камилләштерү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 маддәсе, Россия Федерациясе Җир кодексының 84 маддәсе, «Магистраль торбалар» СНиП 2.05.06-85 3.16 п. таләпләре, шәһәр Уставының 19 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын (алга таба – Шәһәр Советы карары проекты) халык яши торган пункт чикләрен үзгәртү һәм халык яши торган пункт җирләреннән сәнәгать территорияләрен чыгару өлешендә кушымтадагыча хупларга һәм гавами тыңлауларда карап тикшерүгә куярга.

2. Шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү көнен 2016 елның 26 маена тәгаенләргә, үткәрү вакытын 14.00 сәгатькә, гавами тыңлауларны үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасын (Х.Туфан проспекты, 23 йорт), 400 залны билгеләргә.

3. Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү буенча гавами тыңлаулар үткәрү комиссиясенә әлеге карарның һәм Шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында хәбәрнең «Челнинские известия» газетасында басылып чыгуын һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырылуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
7/8 нче Карарына
кушымта
7 апрель, 2016 ел

# ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ СЫЗЫМЫ

## ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ СЫЗЫМЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ («ТРАНСНЕФТЬ-ПРИКАМЬЕ» АҖ ОБЪЕКТЫ БУЕНЧА ХАЛЫК ЯШИ ТОРГАН ПУНКТ ЧИКЛӘРЕН ҮЗГӘРТҮ ӨЛЕШЕНДӘ)

